ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» октябрь 2024 ел № 274

Гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм аларны Татарстан Республикасы Әгерҗе шәһәре һәм Әгерҗе муниципаль районы буенча социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен 2024 елның III-IV кварталына торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында

«Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 13.07.2007 елның 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына бәяләү эшчәнлегенә бәйле эксперт һәм консультация ярдәмен гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында коммерциягә карамаган оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты чаралары исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 19.11.2021 елның 1104 номерлы карары, «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 03.10.2019 елның 888 номерлы карары нигезендә, «Бәяләр диапазонын билгеләү турында» 2024 елның 15 августындагы 252 номерлы «Татарстан Республикасы Бәяләүчеләр берлеге» коммерцияле булмаган партнерлыгының хатын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның III-IV кварталына Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә гражданнарны аз керемлеләр дип тану һәм социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә алу өчен торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясе түбәндәге күләмнәрдә расларга:

- Әгерҗе шәһәре буенча 41 524,50 сум (Кырык бер мең биш йөз егерме дүрт сум илле тиен);

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 01.07.2024 елда барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.М. Латыйповка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**